# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 23 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 23 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2023 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:
1. махсуслаштырылган техниканы карап тоту «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
2. Зур Нөркәй авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту утларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);
3. Зур Нөркәй авылында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;
4. Зур Нөркәй авылында бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне);
5. Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
6. «Сарман» район газетасында некрологлар бастыру;
7. Зур Нөркәй авылында С.Рәфыйков урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш салу белән чокырларны ремонтлау, таш ташу) ;
8. Зур Нөркәй торак пунктында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 378 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 205 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 205 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл жирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзаларыннан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1. махсуслаштырылган техниканы карап тоту «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);

2. Зур Нөркәй бистәсендә урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту утларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);

3. Зур Нөркәй бистәсендә җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;

4. Зур Нөркәй авылында бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне);

5. Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

6. «Сарман» район газетасында некрологлар бастыру;

7. Зур Нөркәй бистәсендә С.Рәфыйков урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш салу белән чокырларны ремонтлау, таш ташу) ;

8. Зур Нөркәй торак пунктында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче — Р.М.Гайсин